# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге составына керүче Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пунктында 2023 елга үзара салым кертү турында

№ 1 17 октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгында) торак пунктында урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар алу һәм урнаштыру;
- Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгында) торак пунктында скважинаны чистарту буенча эшләр үткәрү (килешү буенча эш өчен түләү);
- Норма урманчылыгы -Лесная урамында юлларны вак таш җәеп ремонтлау. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Су-Елга торак пунктында (шул исәптән Норма урманчылыгында) гидрантлар өчен янгын колонкалары һәм янгын җиһазлары сатып алу;
- Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгында) торак пунктындагы юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Кече Кирмән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Х.Х.Мубаракшин